| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2024 г.Казань № 536-120/кс-2024

Түбән Кама муниципаль районының «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте өчен 2025-2027 елларга су (җитештерү агынтыларын) чыгаруга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмаларның инвестиция һәм җитештерү программалары турында» 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 17.12.2024 ел, №34-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Билгеләргә:

Түбән Кама муниципаль районының су чыгаруны гамәлгә ашыручы «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Нижнекамскнефтехим» ГАҖ) өчен әлеге карарның 1-2 нче кушымталары нигезендә су (җитештерү агынтыларын) чыгаруга календарь буенча бүленгән тарифлар;

әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә 2025 – 2027 елларга су агызуны гамәлгә ашыручы «Нижнекамскнефтехим» ГАҖ өчен су (җитештерү агынтыларын) чыгаруга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрларын.

2. Әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә «Нижнекамскнефтехим» ГАҖ су агызу өлкәсендәге җитештерү программасын расларга.

3. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2027 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

4. Ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Нижнекамскнефтехим» ГАЖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2024 № 536-120/кс-2024
карарына 1 нче кушымта

Су чыгаруны гамәлгә ашыручы «Нижнекамскнефтехим» ГАҖ 2025 елга су (җитештерү агынтыларын) чыгаруга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ташландык су (җитештерүдә агып җыелган суларны) агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | |
| 1 | «Нижнекамскнефтехим» ГАҖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 12,58 | 13,77 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
_______________ № ______________
карарына 2 нче кушымта

Су чыгаруны гамәлгә ашыручы «Нижнекамскнефтехим» ГАҖ 2026-2027 елларга* су (җитештерү агынтыларын) чыгаруга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Чор | Ташландык су (җитештерүдә агып җыелган суларны) агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Түбән Кама муниципаль районы | | |
| 1 | «Нижнекамскнефтехим» ГАҖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 10,75 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 10,75 |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 10,75 |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 17,71 |

* 2026-2027 елларга ташландык су (җитештерүдә агып җыелган суларны) чыгаруга тарифларга ел саен төзәтмәләр кертү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары нигезендә уздырыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
________________ № __________
карарына 3 нче кушымта

2025 – 2027 елларга су агызуны гамәлгә ашыручы «Нижнекамскнефтехим» ГАҖ өчен су (җитештерүдә агып җыелган суларны) чыгаруга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары

| т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе* | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе** | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе*** | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | "Нижнекамскнефтехим" ГАҖ | | | | | | |
| 1.1 | Су чыгару (җитештерүдә агып җыелган сулар) | 2025 | 63 158,12 | х | - | - | 0,672 |
| | | 2026 | - | 1 | - | - | 0,672 |
| | | 2027 | - | 1 | - | - | 0,672 |

* Озак сроклы җайга салуның икенче һәм аннан соңгы елларына операция чыгымнарының база дәрәҗәсе Россия ФТХ 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы белән расланган Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрнең 45 пунктында каралган формула буенча исәпләнә.
** «Нижнекамскнефтехим» ГАҖ өчен норматив табыш дәрәҗәсе билгеләнми.
*** Су агызуга тариф өчен «су югалту дәрәҗәсе» энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткече билгеләнми.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
_______________ № ___________
карарына 4 нче кушымта

## Оешманың җитештерү программасы

### 1 нче бүлек. Җитештерү программасы паспорты

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Җайга салынулы оешма** | "Нижнекамскнефтехим" ГАҖ | | | |
| Урнашкан урыны | 423574, Татарстан Республикасы, Түбән Кама районы, Түбән Кама шәһәре, Соболековская урамы, 23 бина, 129 офис. | | | |
| **Җайга салуның вәкаләтле органы** | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | | | |
| Урнашкан урыны | 420015, Казан ш., Карл Маркс ур., 66 й. | | | |
| **Җитештерү программасын гамәлгә ашыру чоры** | башлана | 01.01.2025 | тәмамлана | 31.12.2027 |

### 2 нче бүлек. Су белән тәэмин итүнең һәм ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системалары объектларын ремонтлау чаралары, эчә торган суның сыйфатын һәм агып төшүче суларны чистарту сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән транспортировкада су югалтуларын киметү чаралары исемлеге

| **№** | **Аталышы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Гамәлгә ашыруга финанс ихтыяҗлары** | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | **2025** | **2026** | **2027** |
| 1ВО - Ташландык суларны - җитештерүдәге агынты суларны агызуга тариф | | | | | |
| 1 | Агымдагы ремонт | мең сум | 11 422,78 | 11 791,47 | 12 143,41 |
| 2 | Капиталь ремонт | мең сум | 13 711,45 | 14 154,01 | 14 576,46 |
| 3 | Башка чаралар, шул исәптән агып төшүче суларны чистарту сыйфатын яхшыртуга, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 |

### 3 нче бүлек. Су бирү күләме/Кабул ителгән су

1ВО - Ташландык суларны - җитештерүдәге агынты суларны агызуга тариф

| № | Җитештерү эшчәнлеге күрсәткечләре | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч зурлыгы | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2025 | 2026 | 2027 |
| 1 | Агынты суларны кабул итү, шул исәптән: | мең м3 | 9 221,37 | 9 221,37 | 9 221,37 |
| 2 | предприятиенең үз ихтыяҗлары | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 3 | Хезмәтләрне җибәрү (гамәлгә ашыру), барысы да, шул исәптән: | мең м3 | 9 221,37 | 9 221,37 | 9 221,37 |
| 3.1 | бюджет оешмаларына | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 3.2 | халыкка | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 3.3 | башка кулланучылар | мең м3 | 9 221,37 | 9 221,37 | 9 221,37 |
| 3.4 | башка канализацияләрдән кабул ителгән агынты сулар | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 4 | Агынты суларның исәпкә алынмаган агымы | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 5 | Транспортлана торган агынты сулар күләме | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 5.1 | Үз чистарту корылмалары аша үткәрелгән | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 5.2 | Башка канализацияләргә тапшырылган агынты сулар | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 6 | Чистарту корылмалары белән җиһазландырылмаган су чыгару торбалары аша үткәрелгән агынты су күләме | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |

**4 нче бүлек. Җитештерү программасын гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс ихтыяҗлары күләме**

| № | Күрсәткеч | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч зурлыгы | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2025 | 2026 | 2027 |
| 1 | Җитештерү чыгымнары | мең сум | 50 032,06 | 52 251,37 | 53 289,71 |
| 1.1 | Төп җитештерү персоналының хезмәте өчен түләү һәм социаль ихтыяҗларга чигерү чыгымнары, шул исәптән салымнар һәм җыемнар: | мең сум | 9 765,11 | 10 080,30 | 10 381,16 |
| 2 | Ремонт чыгымнары | мең сум | 31 311,78 | 32 322,42 | 33 287,14 |
| 3 | Административ чыгымнар | мең сум | 4 583,34 | 4 731,27 | 4 872,48 |
| 4 | Сату чыгымнары | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 5 | Амортизация | мең сум | 25 862,22 | 25 862,22 | 25 862,22 |
| 6 | Аренда һәм концессия түләүләре, лизинг түләүләре | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 7 | Салымнар һәм җыемнар | мең сум | 13 886,19 | 13 886,19 | 13 886,19 |
| 8 | Норматив табыш | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 8.1 | Капиталь чыгымнар | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 9 | Гарантияләүче оешманың исәпләмә эшкуарлык табышы | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 10 | Узган чорларның алынмаган керемнәре / чыгымнары | мең сум | 25 735,38 | 0,00 | 0,00 |
| 10.1 | Узган чорда тарифлар билгеләгәндә тарифларны җайга салу органы | мең сум | 8 594,46 | 0,00 | 0,00 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | тарафыннан исәпкә алынмаган икътисадый нигезләнгән чыгымнар | | | | |
| 10.2 | Җайга салуның узган чорларында алынмаган керемнәр | мең сум | 17 140,82 | 0,00 | 0,00 |
| 10.3 | Акча җитмәүне каплауга юнәлдерелгән заем акчаларына һәм үз акчаларына хезмәт күрсәтүгә бәйле чыгымнар | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 11 | Җайга салуның узган чорларының икътисадый нигезләнмәгән керемнәре / чыгымнары | мең сум | 29 940,55 | 29 940,55 | 0,00 |
| 12 | Кирәкле тулай табыш | мең сум | 121 470,32 | 99 112,93 | 131 197,75 |
| **5 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру графигы** | | | | | |
| **№** | **Чараның аталышы** | **План чоры** | | | |
| 1 | Су агызу челтәрләрен агымдагы ремонтлау | 2025-2027 | | | |
| 2 | Капиталь ремонт | 2025-2027 | | | |
| **6 нчы бүлек. Су белән тәэмин итүнең һәм ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты һәм энергетик нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләре** | | | | | |
| **№** | **Күрсәткеч** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** | | |
| | | | **2025** | **2026** | **2027** |
| 1ВО - Ташландык суларны - җитештерүдәге агынты суларны агызуга тариф | | | | | |
| 1 | Агынты суларны чистарту сыйфаты күрсәткечләре | | | | |
| 1.1 | Дсвно – Үзәкләштерелгән гомуми агызу яисә көнкүреш су агызу системаларына ташлана торган агынты суларның гомуми күләмендә чистартылмый торган агынты су өлеше | % | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 1.2 | Днн – Ташландык суларны ташлауның билгеләнгән нормативларына, ташландык суларны ташлау лимитларына туры килми торган агынты су пробаларының үзәкләштерелгән гомуми агызу (көнкүреш) системасы төренә карата исәпләнгән өлеше | % | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 2 | Су агызуның ышанычлылык һәм өзлексезлек күрсәткечләре | | | | |
| 2.1 | Пн – Канализация челтәренең озынлыгына исәпләгәндә аварияләрнең һәм чүп-чарларның чагыштырма саны | бер./км | - | - | - |
| 3 | Энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | | | | |
| 3.1 | Урост – технологик процесста кулланыла торган электр энергиясенең чагыштырма чыгымы | кВт*сәг/куб.м | 0,672 | 0,672 | 0,672 |
| 3.2 | Урп – Эчә торган су әзерләүнең технологик процессында кулланыла торган электр энергиясе челтәргә җибәрелә торган су күләме берәмлегенә чагыштырма чыгымы | кВт*сәг/куб.м | | | |

| 7 нче бүлек. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты һәм энергетик нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләренең һәм җитештерү программасын гамәлгә ашыру чыгымнарының анык гамәлдә булу чоры дәвамында үзгәреш динамикасын чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла торган җитештерү программасының нәтиҗәлелеген исәпләү | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **№** | **Күрсәткеч** | **Үлчәү берәмлеге** | **Планлаштырыла торган чор күрсәткече зурлыгы** | | |
| | | | **2025** | **2026** | **2027** |
| 1ВО - Ташландык суларны - җитештерүдәге агынты суларны агызуга тариф | | | | | |
| | Үзгәреш динамикасын чагыштыру | % | Ышанычлылык, сыйфат һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләре үзгәрешсез билгеләнә | | |
| **8 нче бүлек. Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турында хисап** | | | | | |
| Оешма 2023 елда су агызу эшчәнлегенең җайга салынулы төрен гамәлгә ашырмады | | | | | |
| **9 нчы бүлек. Абонентларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар** | | | | | |
| № | Абонентларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар каралмаган | | | | |